

«Һонәре буенча ин яхшысы» конкурсында катнашучылар арасында «Газпром газ бvлv Саранск» жәмгыятчелегенен Темников шәһә-рендәге филиалы вәкилләре бар иде (ул оч районга хезмәт кvрсәтә: Темниковский, Теньгушевский, Ельниковский). Конкурсантлар торле катлаулыктагы биремнәрне vтәгәннәр, һонәр осталыкларын кvрсәткәннәр һәм оч номинациянен һәркайсында призлы урын да алганнар.       - Безнен оешмада һонәри осталык конкурсы ел саен vткәрелә, - ди «Газпром газ бvлv Саранск»нын Темников шәһәрендәге филиалы житәкчесе Фарид Набиулла улы Урусов. - Эретеп ябыштыручылар арасында һәрвакыт ин яхшыларны гына билгели идек. Әмма быел ин яхшы слесарьларны да, ин яхшы машина йортvчеләрне дә сайладык. Моны гадел карар дип саныйм, чонки бу һонәр вәкилләренен осталык дәрәжәсенә таләпләр арта. Ин яхшыларны ачыклау тәжрибәне хезмәттәшләр арасында тарату очен кирәк.
Конкурс ике этапта уздырылды һәм ике олештән торды: теоретик -тестлаштыру Темниковта иде һәм практик - конкрет биремне vтәv Саранскта булды. Топ критерийлар - вакыт һәм сыйфат.
«Йорт эчендәге газ жиһазлары хезмәтенен ин яхшы слесаре» номинациясендә республика буенча икенче призлы урын Ринат Урусовка бирелде. Хезмәттә белгеч 11 ел эшли. Газ жиһазларынын тозексезлекләрен эзләv, аларны бетерv, шулай ук газ казаннарына һәм плиталарына техник хезмәт кvрсәтv - анын турыдан-туры хезмәт бурычлары, шуна кvрә биремне ул оста башкарган. Хәер, икенче урын - беренче урын тvгел һәм ана омтылырлык нәрсәләр бар.
 - Конкурста беренче тапкыр катнаштым, - дип сойли Ринат Наиль улы Урусов. - Әлбәттә, дулкынландым. Беренче чиратта житәкчелекне һәм коллективны унайсыз хәлгә куярга курыктым. Барысы да бик житди иде: комиссия, бернинди «шпаргалкалар» юк, тирә-юньдә видеокvзәтv. Практик биремне тиз һәм сыйфатлы башкардым. Әмма киләсе елда беренче урынны алу очен теорияне ойрәнергә кирәк.
«Полиэтилен торбаларны эретеп ябыштыру буенча ин яхшы бригада» номинациядә эретеп ябыштыручылар Руслан Хозин һәм Сергей Соколов катнашты. Алар команда. Теоретик сорауларга жавап биреп, алар зур диаметрлы (160 мм) полиэтилен торбанын контроль тоташуын эретеп ябыштырганнар. Алынган нәтижә бригаданы мактау пьедесталында оченче урынны билгеләп.
- Ярыш шартлары таныш. Барысына да кvнеккән, барысы да билгеле, жиһазларны vзебезнекен кулландык, - диләр конкурсантлар. Ләкин хезмәт коннәрендә без бу эшне ашыкмыйча эшлибез (тоташтыргычны эретеп ябыштыруга бер сәгать чамасы вакыт китә), ә анда барысын да момкин кадәр тизрәк эшләргә кирәк иде. Без яхшы тәжрибә тупладык. Эшебезне яратабыз. Осталыкны камилләштерәчәкбез.
«Ин яхшы машина йортvче» номинациясендә оченче урынны Александр Михалин алган. Ул юл хәрәкәте кагыйдәләрен белv имтиханын бик яхшы тапшырган һәм автомобиль йортv буенча мастер-класс та кvрсәткән.
Мондый конкурснын топ максаты - һонәри осталыкны кvрсәтv. Темниковлылар vзләренен республикада ин яхшылардан булуын исбатлаганнар.

Фотода: «Ин яхшы слесарь» - Ринат Урусов; «Ин яхшы машина йортvче» - Александр Михалин; «Ин яхшы бригада» - Руслан Хозин белән Сергей Соколов.

**Наилә НАСЫРОВА**